ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
ЗЕЛЕНОДОЛЬСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ЗЕЛЕНОДОЛЬСК
МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫНЫҢ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

---

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ**
**07.04.2018**

Зеленодольск
шәһәре

**КАРАР**
**№ 803**

2018 елга гражданнар кеременең һәм салым салынырга тиешле мөлкәт хакының иң чик күләмнәрен раслау турында

«Татарстан Республикасы дәүләт торак фондыннан һәм муниципаль торак фондыннан социаль наем шартнамәләре буенча гражданнарның аларга торак урыннары бирү хокукларын гамәлгә ашыру турында» 2007 елның 13 июлендәге 31-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы нигезендә һәм Гаиләнең һәр әгъзасына яки ялгыз яшәүче гражданга туры килә торган керемнең һәм гаилә әгъзалары яисә ялгыз яшәүче граждан милкендә булган һәм салым салынырга тиешле мөлкәт хакының иң чик күләмнәрен билгеләү методикасы, күрсәтелгән законга кушымтада бәян ителгәннәрдән чыгып, Россия Федерациясе Төзелеш һәм торак-коммуналь хуҗалыгы министрлыгының «Россия Федерациясе буенча торак урынның гомуми мәйданының 2018 елның беренче яртыеллыгына бер квадрат метрның бәясе нормативы һәм 2018 елның I кварталына Россия Федерациясе субъектлары буенча торак урынның гомуми мәйданының бер квадрат метрның уртача базар хакы күрсәткечләре турында» 2017 елның 20 декабрендәге 1691/пр боерыгы белән, шулай ук Россия Федерациясе Торак кодексының 91.3 статьясына таянып, Зеленодольск муниципаль районы Башкарма комитеты

**КАРАР БИРӘ:**

1. 2018 елга гражданнарны аз керемлеләр дип тану турында карар кабул итү өчен түбәндәге иң чик күрсәткечләрне билгеләргә:

1.1. гаилә әгъзалары (ялгыз яшәүче граждан) милкендәге һәм салым салынырга тиешле милек хакының иң чик күләме:

1.1.1. ялгыз яшәүче граждан өчен - 1 233 474 сум;

1.1.2. ике кешедән торган гаилә өчен - 1 569 876сум;

1.1.3.өч кешедән торган гаилә өчен - 2 018 412 сум;

1.1.4. дүрт кешедән торган гаилә өчен - 2 691 216 сум;

1.1.5. биш  кешедән торган гаилә өчен - 3 364 020 сум;

1.1.6. алты кешедән торган гаилә өчен - 4 036 824 сум;

1.1.7.җиде кешедән торган гаилә өчен - 4 709 628 сум;

1.2. гаиләнең һәр әгъзасына туры килә торган уртача айлык җыелма керем күләме:

1.2.1 ялгыз яшәүче граждан өчен - 13 416,67 сум;

1.2.2.ике кешедән торган гаилә өчен - 8 537,888сум;

1.2.3. Өч һәм аннан да күбрәк кешедән торган гаилә өчен - 7 318,18 сум.

2. Торак урыннарына мохтаҗлар буларак исәпкә куйганда «ЗМР Торак сәясәте департаменты» МКУ муниципаль торак фонды бүлегенә әлеге карарның 1.1 һәм 1.2 пунктчаларында күрсәтелгән иң чик күрсәткечләрне кулланырга.

3. Зеленодольск муниципаль районы Советы Аппаратының җәмәгатьчелек һәм ММЧ белән элемтә начальнигына әлеге карарны массакүләм мәгълүмат чараларында бастырып чыгарырга һәм Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында (http://pravo.tatarstan.ru) һәм Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләре порталы составындагы Зеленодольск муниципаль районының мәгълүмати сайтында (http://zelenodolsk.tatarstan.ru)Интернет челтәрендә урнаштырырга.

4. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз җаваплылыгымда калдырам.

Җитәкче А.Х. Сәхибуллин

**2018 елга гаиләнең һәр әгъзасына яисә ялгыз яшәүче гражданга туры килә торган керемнең һәм гаилә әгъзалары яисә ялгыз яшәүче граждан милкендә булган һәм салым салынырга тиешле мөлкәт хакының чик күләмен билгеләү**

**МЕТОДИКАСЫ**

**1. Базар бәясенең исәп-хисап күрсәткече**

**СЖ= НП*РС* РЦ, биредә**

СЖ-базар бәясенең исәп-хисап күрсәткече яки мөлкәт хакының иң чик күрсәткече;

НП – гаиләнең бер әгъзасына торак урыны бирү нормасы;

РС-гаилә әгъзалары саны;

РЦ - РФ Төзелеш һәм торак-коммуналь хуҗалык министрлыгы тарафыннан расланган 1 кв.м. мәйданның уртача исәп-хисап базар бәясе (2018 елның беренче кварталына - 37 378 сум)

а) ялгыз яшәүче граждан өчен:

СЖ= 37 378 *33= 1 233 474

б) ике кешедән торган гаиләгә:

СЖ=37 378 *42= 1 569 876

в) өч кешедән торган гаиләгә:

СЖ=37 378 *18*3= 2 018 412

г) дүрт кешедән торган гаиләгә:

СЖ=37 378 *18*4= 2 691 216

д) биш кешедән торган гаиләгә:

СЖ=37 378 *18*5= 3 364 020

ж) алты кешедән торган гаиләгә:

СЖ=37 378 *18*6= 4 036 824

з) җиде кешедән торган гаиләгә:

СЖ=37 378 *18 = 7= 4 709 628

**2. Гаиләнең һәр әгъзасына туры килә торган уртача айлык җыелма керемнең иң чик күләме**

**ПД=0,7*СЖ*ПС/ {1-[(1+ПС) - КП]/ (0,3*РС), анда**

СЖ-социаль наем шартнамәсе буенча торак урын бирү нормасы буенча торак урын сатып алуның базар хакының исәп-хисап күрсәткече;

ПС - бер айга кредит буенча процент ставкасы (14/12);

КП -бөтен кредит срогына кредит буенча түләүләрнең гомуми саны ( айлар саны);

РС-гаилә әгъзалары саны;

0,7-кредит суммасы һәм фатир бәясе нисбәте;

0,3 — гаиләнең гомуми айлык кереме белән кредит буенча түләү нисбәте

а) ялгыз яшәүче граждан өчен:

ПД=(0,7*1 233 474 *1,16) / {1-[(1+1,16) - 250]/ (0,3*1)= 13 416,67

б) ике кешедән торган гаиләгә:

ПД=(0,7*1 569 876*1,16) / {1-[(1+1,16) - 250]/ (0,3*2) = 8 537,88

в) өч һәм аннан да күбрәк кешедән торган гаиләгә:

ПД=(0,7*2 018 412*1,16)/ {1-[(1+1,16) - 250]/ (0,3*3)= 7 318,18

г) дүрт һәм аннан да күбрәк кешедән торган гаиләгә:

ПД=(0,7*2 691 *216 *1,16)/ {1-[(1+1,16) - 250]/ (0,3*4)= 7 318,18

« Зеленодольск муниципаль районы
Торак сәясәте департаменты »" МКУ җитәкчесе Ж.Е. Багабиева